РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

---

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 45

2020 елның 20 мае

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Майская Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы беренче өлешенең 20 пункты, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясындагы беренче өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошинның 2020 елның 24 апрелендәге 10-53/5220 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге генераль планына үзгәрешләр кертү проектына бәяләмә нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2017 елның 24 гыйнварындагы 8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертүне расларга.
2. Әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.
3. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш һәм архитектура идарәсенә расланган документны Россия Федерациясе территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

А.Р.Метшин